ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**V чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**V созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.11.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№02-04

Актаныш муниципаль районы Советы карары проекты
2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Актаныш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе А.А.Корбангалинаның Актаныш муниципаль районы бюджетының 2025 елның 9 аена үтәлеше турындагы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 1 336 866,6 мең сум күләмендә, төгәлләштерелгән план буенча 1 637 937,4 мең сум, чыгымнар буенча 1 320 813,6 мең сум күләмендә, төгәлләштерелгән план буенча 1 640 608,9 мең сум күләмендә, профицит белән 16 053,0 мең сум, төгәлләштерелгән план белән дефицит белән 2 671,5 мең сум күләмендә расларга;

2. 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын 1 нче кушымта нигезендә расларга;

3. 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразланган күләмен 2 нче кушымта нигезендә расларга;

4. 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 3 нче кушымта нигезендә расларга;

5. 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 4 нче кушымта нигезендә расларга;

6. Бюджет ассигнованиеләрен 2025 елның 9 аена Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне 5 нче кушымта нигезендә расларга.

7. 2025 елның 9 аена "Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны" 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

8. Әлеге карар Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aknysh.tatarstan.ru урнаштырылырга һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырылып чыгарылырга тиеш.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов